ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 151-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова, Е.И. Кузьмичева, А.С. Созинов, И.Г. Хәнипов, В.Г. Чагин тарафыннан кертелгән «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 151-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 568-VII ДС

157-2

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
О.М. Воронова,
Р.С. Гайнетдинова,
Е.И. Кузьмичева,
А.С. Созинов,
И.Г. Хәнипов,
В.Г. Чагин
тарафыннан кертелә

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ өлештә «филиаллары һәм вәкиллекләре» сүзләрен «вәкиллекләре, филиаллары һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

2) $1^2$ өлештә «филиалларына һәм вәкиллекләренә» сүзләрен «вәкиллекләренә, филиалларына һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләренә» сүзләренә алмаштырырга, «филиаллары һәм вәкиллекләре» сүзләрен «вәкиллекләре, филиаллары һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 өлештә «филиалының» сүзеннән соң «һәм башка аерымланган структур бүлекчәсенең» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Закон проектында тәкъдим ителә торган үзгәрешләр инвалидларның мәшгульлеген һәм хезмәт гарантияләрен тәэмин итү тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән.

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының гамәлдәге редакциясе инвалидларны эшкә алу өчен квота Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эш бирүчеләр өчен, эш бирүченең Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, алдагы кварталга хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан чыгып билгеләнүен күздә тота.

Закон проекты белән күрсәтелгән норманың гамәлдә булуын эш бирүчеләрнең филиаллары һәм вәкиллекләре булмаган башка аерымланган структур бүлекчәләренә дә тарату тәкъдим ителә.

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар таләп итми.